Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

___20.02.2026______

Менделеевск шәһәре

№ ___117____

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар
белән эшләү буенча тармакара координацияләүне
таләп итә торган мәсьәләләрне карау өчен
ведомствоара муниципаль комиссия төзү турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законының 9 статьясына, «Россия Федерациясендә гражданнарның социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль законына, «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законының 24 статьясының 2 өлешенә, «Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать хакимиятен оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законының 33 статьясының 1 һәм 2 пунктларына ярашлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар белән эшләү буенча тармакара координацияләүне таләп итүче мәсьәләләрне карау өчен ведомствоара муниципаль комиссиясен булдырырга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында билгеле яшәү урыны булмаган затлар белән эшләү буенча тармакара координацияләүне таләп иткән мәсьәләләрне карау комиссиясе турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар белән эшләү буенча тармакара координацияләүне таләп иткән мәсьәләләрне карау комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://mendeleevsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Искаков

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 20 февралендәге
117 номерлы карарына
1 кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар белән эшләү буенча тармакара координацияләүне таләп иткән мәсьәләләрне карау комиссиясе турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар белән эшләү буенча тармакара координацияләүне таләп итүче мәсьәләләрне карау өчен Комиссия (алга таба - Комиссия) Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары каршындагы киңәшмә органы булып тора, һәм ул билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган кешеләр белән эшләү буенча килешенгән гамәлләрне тәэмин итү максатыннан булдырылган

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты һәм Хөкүмәте актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары

Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә сукбайлык һәм хәерчелекне кисәтү чараларын гамәлгә ашыру буенча координацияләнгән гамәлләрне планлаштыру һәм үткәрү

2. Билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган кешеләрне ачыклау һәм теркәүне оештыру.

3. Билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган кешеләрдә килеп чыккан проблемалар буенча аналитик эш.

4. Билгелебер  яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган кешеләргә социаль ярдәм күрсәтү системасын үстерү.

5. Билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган кешеләрне вакытлыча яки даими яшәү урынына урнаштыру эшен координацияләү.

6. Билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган кешеләргә социаль ярдәм күрсәтү мәсьәләсен хәл итүдә җәмәгать һәм хәйрия оешмаларының үзара хезмәттәшлеген һәм эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү.

## 3. Комиссиянең хокуклары

Комиссия хокуклы:

1. Менделеевск муниципаль районы территориясендә сукбайлыкны кисәтү һәм билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган кешеләр белән башкарылган эшләр турында тиешле структур бүлекчәләр җитәкчеләрен, башка ведомстволарны үз утырышларында чакырып тыңлау.

2. Менделеевск муниципаль районы территориясендә билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган кешеләрнең караучысызлыгын профилактикалау һәм аны кисәтү мәсьәләләре буенча барлык кызыксынган органнарга, оешмаларга тәкъдим итү характерындагы карарлар кабул итү.

3. Билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган кешеләрнең караучысызлыгын, сукбайлыгын профилактикалау өлкәсендә эшчәнлек алып баручы ведомстволар, учреждениеләр һәм оешмалар эшен камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертү.

## 4. Комиссия эшчәнлеге

1. Комиссиянең составы һәм Нигезләмәсе Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

2. Комиссия рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

Комиссия рәисенең бер урынбасары бар, ул рәис булмаганда аның функцияләрен башкара.

3. Комиссия утырышлары кирәк булган очракта Комиссия рәисе яки аның урынбасары җитәкчелегендә үткәрелә.

Комиссия утырышлары, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала.

Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән, тавыш бирүдә катнашучы Комиссия әгъзаларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, хәлиткеч тавыш Комиссия рәисенеке була. Карарлар утырышта рәислек итүче тарафыннан имзаланган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 20 февралендәге
117 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар белән эшләү буенча
тармакара координацияләүне таләп итүче мәсьәләләрне карау комиссиясе
составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе: | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Рәис урынбасары | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Менделеевск муниципаль районындагы башлыгы (килешү буенча) |
| Секретарь | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Менделеевск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге консультанты (килешү буенча) |
| Комиссия әгъзалары: | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы |
| | «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» МКУ башлыгы |
| | «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МКУ башлыгы |
| | «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы |
| | «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ җитәкчесе (килешү буенча) |
| | «Менделеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| | «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында "Өмет яры" халыкка социаль хезмәт күрсәтү |

комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе директоры (килешү буенча)

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында муниципаль психологик-педагогик хезмәт җитәкчесе (килешү буенча)

Татарстан Республикасы буенча "Россиянең Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең җинаять-башкарма инспекциясе идарәсе" Федераль казна учреждениесенең Менделеевск районы буенча филиалы өлкән инспекторы (килешү буенча)

Татарстан Республикасы Менделеевск районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге башлыгы (килешү буенча)

Татарстан Республикасы буенча "Россиянең Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең җинаять-башкарма инспекциясе идарәсе" Федераль казна учреждениесенең 10 нчы номерлы төзәтү колониясе башлыгы (килешү буенча)

Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча)